ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.11.2020 г. М ө с л и м № 548

**«2021 елга «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында»**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2013 елның 30 декабрендәге 1096 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары һәм «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2021 елга түбәндәгеләрне расларга:

«Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

«Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләве күләмен;

2020 елның 1 гыйнварына кадәр мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларында исәпләнгән балага балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналар түләве күләменә карата күчеш чорына төзәтмәләр коэффициентлары кулланыла торган мәктәпкәчә белем бирү программаларын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларының исемлеген;

2020 елның 1 гыйнварына кадәр мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларында исәпләнгән бала өчен ата-аналар түләве күләменә карата (азык-төлек бәясеннән тыш) күчеш чорына төзәтмәләр коэффициентларын.

2. «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасына, әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен финанслау нормативлары нигезендә, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрен финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы М.Р. Бәдретдинова